**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңү Көнен Татарстан Республикасында бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты төзү турында**

1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңү Көненә багышланган еллык тантаналы чараларны Татарстан Республикасында әзерләү һәм уздыруны оештыру максатларында **карар бирәм**:

1. 1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңү Көнен Татарстан Республикасында әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты (алга таба – Оештыру комитеты) төзергә.

2. Оештыру комитеты турындагы нигезләмәне (1 нче кушымта) һәм аның составын (2 нче кушымта) расларга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:
Оештыру комитеты тәкъдимнәрен исәпкә алып, ел саен 1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңү Көнен Татарстан Республикасында бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны уздыру буенча чаралар планын, аларны уздыру вакытын, җаваплы башкаручыларны расларга, шулай ук аны гамәлгә ашыруга контрольне тәэмин итәргә;
әлеге Указны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

4. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына тиешле муниципаль берәмлекләрдә 1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңү Көнен бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитетлары төзергә һәм ел саен чаралар планнарын расларга тәкъдим итәргә.

5. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына 1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңү Көненә

багышланган чаралар уздыруны массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны оештырырга.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2021 ел, 06 май
№ ПУ-349

Татарстан Республикасы
Президентының
2021 елның « 06 » маендагы
ПУ- 349 номерлы Указына
1 нче кушымта

**1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңү Көнен Татарстан Республикасында бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты турында нигезләмә**

1. 1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңү Көнен Татарстан Республикасында бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты (алга таба – Оештыру комитеты) 1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңү Көненә багышланган еллык тантаналы чараларны Татарстан Республикасында әзерләү һәм уздыру максатларында төзелә.

2. Оештыру комитеты үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Оештыру комитеты турындагы нигезләмә һәм аның составы Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана.

4. Оештыру комитетының төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңү Көнен Татарстан Республикасында бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны уздыру буенча чаралар планына (алга таба – Чаралар планы) тәкъдимнәр эшләү;

Бөек Ватан сугышы вакыйгаларын, анда катнашучылар, ветераннар һәм сугыш корбаннары турында хатирәләрне мәңгеләштерү, шулай ук совет халкының Бөек Ватан сугышында Җиңүе турында истәлеккә лаеклы һәм ихтирамлы караш тәэмин итү буенча тәкъдимнәр эшләү;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары), җәмәгать берләшмәләренең һәм оешмаларның Чаралар планын үтәүгә бәйле бурычларын хәл итү буенча эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итү;

Чаралар планын үтәү мәсьәләләрен карап тикшерү һәм аңа төзәтмәләр кертү буенча тәкъдимнәр эшләү.

5. Оештыру комитеты үз алдында торган бурычларны гамәлгә ашыру максатларында түбәндәгеләргә хокуклы:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, җәмәгать берләшмәләреннән һәм оешмалардан Оештыру комитеты компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча мәгълүмати материаллар соратып алырга;

Оештыру комитеты компетенциясенә кергән мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән тәртиптә вакытлыча эш төркемнәре төзергә;

үз утырышларына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, җәмәгать берләшмәләре һәм оешмалар җитәкчеләрен чакырырга.

6. Оештыру комитеты составына Оештыру комитеты рәисе, Оештыру комитеты рәисе урынбасары, Оештыру комитеты секретаре һәм Оештыру комитетының аның эшендә җәмәгать башлангычларында катнашучы әгъзалары керә.

Оештыру комитеты рәисе булып Татарстан Республикасы Президенты тора.

7. Оештыру комитеты утырышлары кирәк булган саен уздырыла.

Оештыру комитеты утырышларын Оештыру комитеты рәисе яисә аның кушуы буенча Оештыру комитеты рәисе урынбасары алып бара.

8. Утырышларның көн тәртибен, аларны уздыру урынын һәм тәртибен Оештыру комитеты рәисе билгели.

9. Оештыру комитеты утырышы, әгәр анда Оештыру комитеты әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, гамәлгә хокуклы дип санала.

Оештыру комитеты утырышында мәсьәләләрне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча карарлар кабул ителә, алар беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Оештыру комитеты карарлары аның утырышында катнашучы Оештыру комитеты әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар саны тигез булганда, Оештыру комитеты рәисе тавышы хәлиткеч була. Оештыру комитеты әгъзасы утырышта катнашмаган очракта, карала торган мәсьәләләр буенча үз фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы, аның фикере Оештыру комитеты утырышы беркетмәсенә мәҗбүри рәвештә теркәлергә тиеш.

Оештыру комитеты утырышы беркетмәсенә Оештыру комитеты секретаре кул куя һәм ул рәислек итүче тарафыннан раслана.

10. Оештыру комитеты тарафыннан кабул ителгән карарлар Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, җәмәгать берләшмәләренә, оешмаларга һәм башка кызыксынган затларга җиткерелә.

Оештыру комитеты карарлары нигезендә Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актлары проектлары әзерләнергә мөмкин.

11. Оештыру комитеты эшчәнлеген матди-техник яктан, документлар белән һәм мәгълүмати тәэмин итүне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты тормышка ашыра.

Татарстан Республикасы
Президентының
2021 елның «_06_» маендагы
ПУ-_349_ номерлы Указына
2 нче кушымта

**1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңү Көнен Татарстан Республикасында бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты составы**

| | |
|---|---|
| Миңнеханов<br>Рөстәм Нургали улы | Татарстан Республикасы Президенты, Оештыру комитеты рәисе |
| Фазлыева<br>Ләйлә Ринат кызы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Бәдриев<br>Илдар Фоат улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе башлыгы, Оештыру комитеты секретаре |
| Айзатуллин<br>Марат Мансур улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры |
| Әюпова<br>Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры |
| Вәлиев<br>Рамил Миргасыйм улы | «Хәтер китабы» редакциясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе баш мөхәррире |
| Вәлиева<br>Зилә Рәхимҗан кызы | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе (килешү буенча) |
| Вафин<br>Эдуард Яфәс улы | Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе идарәчесе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Габдрахманова Гөлнара Зәкәрия кызы | Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе |
| Гайзатуллин Радик Рәүф улы | Татарстан Республикасы финанс министры |
| Гәрәев Раил Рүзәл улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Башкарма хакимият органнары хезмәттәшлеген координацияләү идарәсе башлыгы |
| Гыйльманов Рафаил Вәли улы | Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы Секретаре |
| Глухова Лариса Юрьевна | Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсе башлыгы |
| Горелик Ицхак | Татарстан Республикасы баш раввины (килешү буенча) |
| Гобәйдуллин Әгъзам Самат улы | «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе рәисе (килешү буенча) |
| Демидов Виктор Николаевич | Татарстан Республикасы буенча баш федераль инспектор (килешү буенча) |
| Зарипова Эльмира Әмир кызы | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры |
| Захарова Светлана Михайловна | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Иштирәков Хәбир Газиз улы | Татарстан Республикасы ветераннар (пенсионерлар) төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Кадыйров<br>Рөстәм Раиф улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Административ һәм хокук саклау органнары идарәсе башлыгы |
| Камалтынов<br>Юрий Зимелевич | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Кәримов<br>Альберт Әнвәр улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры |
| Кирилл<br>(Наконечный<br>Михаил Васильевич) | Казан һәм Татарстан митрополиты (килешү буенча) |
| Когогин<br>Сергей Анатольевич | «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Комяков<br>Альберт Павлович | «Бөек Ватан сугышы ветераннары – блокададагы герой-шәһәр Ленинградта яшәүчеләр» Казан шәһәре җирле иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча) |
| Коноплев<br>Александр Юрьевич | Татарстан Республикасының «Ватан» берләшмәсе» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча) |
| Кулаков<br>Кирилл Денисович | Россия Федерациясе Оборона министрлыгының «Казан Кызыл байраклы Жуков орденлы югары танк команда училищесы» федераль дәүләт казна югары хәрби белем бирү мәгариф учреждениесе башлыгы (килешү буенча) |
| Лаврентьев<br>Александр Петрович | Татарстан Республикасы Предприятиеләр һәм сәнәгатьчеләр ассоциациясе (эш бирүчеләрнең төбәк берләшмәсе) президенты (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Лоханов<br>Павел Николаевич | Россия Федерациясе Социаль иминиятлэштерү фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлекчәсе идарәчесе (килешү буенча) |
| Мәганов<br>Наил Өлфәт улы | В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Мәһдиев<br>Наил Гамбәр улы | «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Метшин<br>Илсур Рәис улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Мостюков<br>Илдус Шайхелислам улы | Советлар Союзы Геройлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Геройлары, Хәрби һәм Хезмәт Даны орденнары тулы кавалерларының Татарстан Республикасы иҗтимагый хәйрия оешмасы шәрәфле рәисе (килешү буенча) |
| Нуретдинов<br>Айрат Рәфкать улы | «Таттелеком» гавами акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Погодин<br>Сергей Николаевич | Татарстан Республикасы хәрби комиссары (килешү буенча) |
| Сабурская<br>Сәрия Харис кызы | Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (килешү буенча) |
| Садыйков<br>Марат Наил улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры |
| Сәлимгәрәев<br>Айдар Сәетгәрәй улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Сәмигуллин<br>Камил хәзрәт<br>(Сәмигуллин<br>Камил Искәндәр улы) | Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте мөфтие (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Сәфәров<br>Әсгать Әхмәт улы | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе |
| Терентьев<br>Александр Михайлович | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе |
| Фәттахов<br>Дамир Илдус улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры |
| Хәбибуллин<br>Рафис Җәүдәт улы | Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казалары нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Хәбибуллин<br>Ринат Ришат улы | «Россиянең үлемсез полкы» бөтенроссия иҗтимагый гражданлык-патриотик хәрәкәтенең Татарстан Республикасында төбәк бүлекчәсе штабы җитәкчесе (килешү буенча) |
| Һадиуллин<br>Илсур Гәрәй улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |
| Хәйруллин<br>Айрат Ринат улы | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры |
| Хәйруллин<br>Газинур Гарифҗан улы | Советлар Союзы Геройлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Геройлары, Хәрби һәм Хезмәт Даны орденнары тулы кавалерларының Татарстан Республикасы иҗтимагый хәйрия оешмасы рәисе, Россия Герое (килешү буенча) |
| Хәнифов<br>Фәрит Мөдәррис улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры |

| | |
|---|---|
| Хохорин Артем Валерьевич | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры (килешү буенча) |
| Хөсәенова Зәйтүнә Борһан кызы | Татарстан Республикасының инвалидлар – балигъ булмаган яшьтәге элеккеге фашистлык тоткыннары иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча) |
| Черепанов Михаил Валерьевич | Татарстан Республикасы Милли музее филиалы – 1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы музей-мемориалы өлкән фәнни хезмәткәре (килешү буенча) |
| Шиһабетдинов Руслан Альберт улы | «ТАИФ» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Юлашев Әхәт Гайнулла улы | «Россия Ветераннар берлеге» гомумроссия ветераннар иҗтимагый оешмасының «Татарстан Республикасы Ветераннар берлеге» республика ветераннар (инвалидлар) иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча) |

___________